**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «ӘҖМӘКӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

«25» апрель 2019 ел № 46/2

«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Әҗмәкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2005 елның 30 декабрендәге «Тукай муниципаль районы «Әҗмәкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы депутаты статусы турында нигезләмәне раслау хакында» 17 санлы карарына үзгәрешләр кертү турында»

---

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ санлы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ санлы Федераль законнар нигезендә Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге Советы

## КАРАР БИРДЕ:

1. Тукай муниципаль районы «Әҗмәкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2005 елның 30 декабрендәге 17 санлы карары белән расланган Тукай муниципаль районы «Әҗмәкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы депутаты статусы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 Әлеге Нигезләмәнең 17 маддәсе 4 өлеше 2 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«2) шәхси яки ышанычлы затлар аша эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шөгыльләнергә, коммерция оешмасы белән идарә итүдә яки коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга (сәяси партия белән идарә итүдә катнашудан тыш); һөнәр оешма органы белән, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органы белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу; башка иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары, күчемсез милекчеләр ширкәтләренең съездында (конференциядә) яки гомуми җыелышында катнашу; эшкә алучы (эш бирүче) вәкиленнән муниципаль актта билгеләнгән тәртиптә алынган рөхсәт белән коммерциясез оешмалар (сәяси партия һәм һөнәри берлек органыннан, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органыннан тыш) белән бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган сыйфатында идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу яки аларның

коллегиаль идарә органнары составына керү, муниципаль берәмлек исеменнән оешманы гамәлгә куючы вәкаләтләрен башкару яки муниципаль милектә булган акцияләр (устав капиталында катнашу өлешләре) белән идарә итү тәртибен билгеләүче муниципаль хокукый актлар нигезендә муниципаль берәмлек гамәлгә куючы (акционер) булып торган оешманың идарә органнарында һәм ревизия комиссиясендә муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тәкъдим итүдән тыш;»

2. Әлеге карарны Әҗмәкәй авыл җирлегендә, мәгълүмати стендларда урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет Рәисе М.Г.Фазылҗанов